РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
АДАВ-ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» сентябрь 2024 ел № 1-86

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай авыл җирлеге Советының «Физик
затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның
6 февралендәге 3-63 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 6 февралендәге 3-63 номерлы карарына (27.05.2024 ел, № 3-82 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-2025 елның 1 гынварыннан 2027 елның 31 декабренә кадәр гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган сәүдә һәм административ-эшлекле (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы билгели торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 1,2 процент;

- 2028 елның 1 гыйнварыннан гомуми мәйданы 1 000 квадрат метрдан артыграк булган сәүдә һәм административ-эшлекле (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы билгели торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 2,0 процент;

- 2025 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнә торган һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата 2,0 процент;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнә торган, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата 2026 елның 1 гыйнварыннан 2,5 процент;

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә 1 ай узгач законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http//buinsk.tatarstan.ru). урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе, Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районының Адав-Толымбай
авыл җирлеге башлыгы А.Ф.Әхмәтҗанов